| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.05.2019 ел Баулы шәһәре №143

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү төзү хокукына аукционның башлангыч бәясен исәпләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына электрон формада торгларны әзерләү һәм үткәрү максатларында, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартында кабул ителгән 38-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2014 елның 19 маенда кабул ителгән 212нче номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү төзү хокукына аукционның башлангыч бәясен исәпләү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Баулы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы Хәсиятуллина Р. И. йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.И. Хөснуллина